| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 сентябрь № 660

г. Казань

Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законның 8 статьясы нигезендә, белем бирү хезмәтләренең сыйфатын яхшырту, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмаларының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга (карарга теркәләләр):

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучы студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр бирү кагыйдәләрен;

Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен.

2. 2016 елның 1 сентябреннән педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стипендия фондын формалаштыру өчен норматив 15,0 мең сум тәшкил итә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле хокукый актлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә бирелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтару механизмын, якларның җаваплылыгын, шартнамәне вакытыннан алда өзү очракларын, шартнамәне үзгәртү һәм өзү тәртибен үз эченә алган укучы шартнамәсе формасын эшләргә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда, мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акча чикләрендә, педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүгә акча бүлергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучы студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр бирү кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр (алга таба – стипендияләр) бирү механизмын билгели.

2. Стипендияләр ел саен педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучы 200 (иң күбе) студентка билгеләнә.

Стипендияләр бөтен уку чорына бер тапкыр билгеләнә.

3. Түбәндәге шартлар үтәлгәндә, студентларның стипендия алу хокукы була:

педагогик кадрларда фаразланган ихтыяҗ нигезендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан ел саен билгеләнә торган әзерлек юнәлешләре (профильләре) буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмаларында көндезге формада бюджет акчасы исәбеннән уку;

студентлар югары белем бирә торган мәгариф оешмасында укыган әзерлек юнәлеше (профиле) буенча Татарстан Республикасының муниципаль мәгариф оешмаларында (алга таба – мәгариф оешмалары) кимендә биш ел эшләү турында укучы шартнамәсендәге йөкләмә. Әлеге вакыт хезмәт шартнамәсе төзегән айның 1сеннән башлап исәпләнә.

4. Беренче курс студентларына беренче аттестациягә кадәр стипендия әлеге Кагыйдәләрнең 8 нче пунктында күрсәтелгән критерийлар нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

Стипендияләр алган беренче һәм аннан соңгы курслар студентларына стипендияләр беренче һәм аннан соңгы аттестацияләр йомгаклары буенча уңай нәтиҗәләр булганда түләнә.

5. Стипендия билгеләү өчен, ел саен, 20 сентябрьгә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары (алга таба – башкарма комитет) Министрлыкка беренче курс студентларына түбәндәгеләрне кертә (килешү буенча):

Министрлык билгеләгән форма буенча башкарма комитет тарафыннан расланган укырга алу турындагы боерыклардан өземтәләрне теркәп, стипендия алуга дәгъва кылучы студентлар исемлекләрен (алга таба – студентлар исемлекләре);

студентларның Министрлык билгеләгән форма буенча стипендияләр бирү турында шәхси гаризалары, түбәндәге документларны теркәп:

урта гомуми белем турында аттестатлар күчермәләре;

студентларның югары белем бирә торган мәгариф оешмасына кергәнче өч ел

дәвамында алган, аларның республика, бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәләрдәге олимпиадаларда катнашуын раслый торган грамоталар һәм дипломнар (булган очракта);

физик затны яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында шаһәдәтнамәләр күчермәләре;

паспорт күчермәләре.

6. Стипендия бирү өчен студентларны сайлап алу турындагы карарны һәм стипендия билгеләү хакында яисә аны бирүдән баш тарту турында карарны Министрлык тарафыннан төзелгән стипендияләр рәвешендә түләүләр билгеләү буенча комиссия (алга таба – комиссия) кабул итә.

7. Әлеге Кагыйдәләрнең 5 нче пунктында билгеләнгән документларны тапшыру вакытлары тәмамланганнан соң 20 эш көненнән артмаган вакыт эчендә Комиссия:

гаризада һәм документларда булган мәгълүматларның тулы һәм дөрес булуын тикшерүне гамәлгә ашыра;

стипендия билгеләү турында яисә стипендия билгеләүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

8. Комиссия бердәм дәүләт имтиханы рәвешендәге керү сынаулары нәтиҗәләре буенча студентлар җыйган баллар суммасы нигезендә стипендия алу өчен сайлап алуны үткән беренче курс студентлары турында карар кабул итә.

Сайлап алу нәтиҗәләре буенча стипендия алуга дәгъва кылучы студентларны баллары кимегән тәртиптә төркемләү гамәлгә ашырыла.

Җыелган баллар тигез булса, урта белем турындагы аттестат буенча иң зур уртача балл һәм студентларның югары белем бирә торган мәгариф оешмасына кергәнче өч ел дәвамында алган, аларның республика, бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәләрдәге олимпиадаларда катнашуын раслый торган грамоталар һәм (яки) дипломнар булуы исәпкә алына.

9. Комиссия түбәндәге очракларда стипендия билгеләүдән баш тарту хакында карар кабул итә:

әлеге Кагыйдәләрнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

әлеге максатларга күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы булмау яки җитмәү;

әлеге Кагыйдәләрнең 5 нче пунктында күрсәтелгән гаризада һәм документларда дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар булуы ачыклану.

Комиссия кабул ителгән карар турында студентларга, карар кабул ителгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә хәбәр итә.

10. Комиссия карары нигезендә Министрлык, карар кабул ителгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә стипендияләр билгеләнгән студентлар исемлекләрен раслау турында боерык (алга таба – боерык) чыгара.

11. Әлеге Кагыйдәләрнең 10 нчы пункты нигезендә, боерык чыккан көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә башкарма комитет (килешү буенча) стипендияләр билгеләнгән студентлар белән Министрлык раслаган форма буенча укучы шартнамәләре төзи.

12. Стипендияләр түләү ай саен һәр айның 20 сенә кадәр әлеге максатларга

Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән башкарыла. Министрлык акчаны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларының шәхси счетларына күчерә. Башкарма комитетлар шәхси счетларына бюджет акчасын алган көннән соң, биш көн эчендә стипендияне студентларның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына күчерә.

13. Стипендия түләү түбәндәге очракларда туктатыла:

студентны югары белем бирә торган мәгариф оешмасыннан чыгару. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хезмәткә чакырылуга бәйле рәвештә чыгарылган очракта, студент югары белем бирә торган мәгариф оешмасында яңадан укый башлаганда, киләсе аттестация йомгаклары буенча стипендия алуга дәгъва кылырга хокуклы;

студентка академик ял бирү. Академик ялдан кайтканда студент киләсе аттестация йомгаклары буенча стипендия алуга дәгъва кылырга хокуклы;

студентның уку йортына йөреп-читтән торып (кичке) уку яки читтән торып уку формасына күчүе яки башка әзерлек юнәлешенә (профиленә) күчүе;

студентның агымдагы аттестациясе йомгакларының әлеге Кагыйдәләрнең 4 нче пунктында билгеләнгән йомгакларга туры килмәве.

14. Стипендия түләү әлеге Кагыйдәләрнең 13 нче пунктында күздә тотылган хәлләр килеп чыккан айдан соң килә торган айның 1 сеннән туктатыла.

15. Башкарма комитетлар әлеге Кагыйдәләрнең 13 нче пунктында күздә тотылган хәлләр килеп чыккан көннән соң биш көн эчендә Министрлыкка язма рәвештә стипендияләр түләүне туктатуга китерә торган хәлләр турында мәгълүмат җибәрә.

16. Әлеге кагыйдәләрнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларда мәгълүматлар үзгәргән очракта, башкарма комитетлар, бу хәлләр килеп чыккан көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлыкка әлеге үзгәрешләрне раслый торган документларны кертә.

17. Укулары тәмамланганнан соң, стипендияләр алган затлар, белем бирү тәмамлануга бәйле рәвештә укучыны чыгару турындагы боерык акты чыккан көннән соң, ике ай эчендә белем бирү оешмасы белән билгеләнгән тәртиптә хезмәт шартнамәсе төзергә тиеш.

Белем бирү оешмасы белән хезмәт шартнамәсе төзегән көннән соң, җиде көн эчендә стипендияләр алган затлар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы билгеләгән форма буенча белем бирү оешмасыннан аларның эшкә урнашу фактын раслый торган белешмәне Министрлыкка кертергә тиеш.

18. Стипендия алган зат эштән киткән очракта, башкарма комитет эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә, эштән китү сәбәбен күрсәтеп, Министрлыкка бу турыда язма рәвештә хәбәр итә.

19. Бирелгән стипендия суммасы, түбәндәге очраклар барлыкка килгән көннән соң, ике ай эчендә законнар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә акча күчерү юлы белән кире кайтарылырга тиеш:

стипендия алган затның әлеге Кагыйдәләрнең 17 нче пунктында билгеләнгән вакытта белем бирү оешмасы белән хезмәт шартнамәсе төземәве;

стипендия алган затның әлеге Кагыйдәләрнең 3 нче пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән вакыттан алда хезмәт шартнамәсен өзүе;

әлеге Кагыйдәләрнең 13 нче пунктында күрсәтелгән сәбәпләр буенча стипендия түләүне туктату.

20. Әлеге Кагыйдәләрнең 19 нчы пунктында күрсәтелгән очраклар килеп чыкканда, Министрлык, башкарма комитет белән берлектә, студентларга стипендияләр рәвешендә бирелгән акчаны кайтару эшен оештыра.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карары белән расланды

Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне (алга таба – стипендия) гамәлгә ашыру максатларында бирелә.

3. Стипендияләр түләү өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләре белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

Министрлык тарафыннан төзелгән стипендияләр рәвешендә түләүләр билгеләү буенча комиссиянең педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларын стипендия бирү өчен сайлап алу турында карар кабул итүе;

Министрлыкның стипендияләр билгеләнә торган студентлар исемлекләрен раслау турында боерыгы булу;

студент һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) арасында фактта төзелгән укучы шартнамәләре булу;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитетының башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны үз вакытында тапшыруы.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен башкарма комитет Министрлыкка

түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык раслаган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза;

гаризага кул куйган затның башкарма комитетка башка бюджетара тарнсфертлар бирүгә вәкаләтләрен раслый торган документ;

белем бирү оешмасының Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язма кертү турында шаһәдәтнамәсе күчермәсе;

фактта төзелгән укучы шартнамәләре күчермәләре.

7. Башкарма комитеттан килгән документлар, алар кертелгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган унбиш көн эчендә Министрлык тарафыннан карап тикшерелә.

Башкарма комитет әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки әлеге Тәртипнең 6 нчы пункты таләпләренә туры килмәгән документлар тапшырган очракта, шулай ук башкарма комитет әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны бирү шартларын үтәмәгән очракта, Министрлык заявканы кабул итми һәм биш көн эчендә, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, башкарма комитетка хәбәр итә.

Башкарма комитет заявканы кире кагу турындагы хәбәрнамәне алган көннән соң 10 көн эчендә, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, кабат заявка тапшырырга хокуклы.

Башкарма комитетның яңадан тапшырылган заявкаларын карап тикшерү тәртибе беренче тапкыр тапшырылган заявкаларны карап тикшерү тәртибе белән бертөрле.

8. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык һәм башкарма комитет арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә.

Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү формасын Министрлык раслый.

9. Муниципаль берәмлек өчен башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

MT= N x 15000 x Q,

монда:

MT – башка бюджетара трансфертлар күләме, сум;

N – муниципаль белем бирү оешмаларында эшләү йөкләмәсе белән фактта укучы шартнамәләре төзегән, педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентлары саны;

15000 –стипендиянең теркәлгән күләме, сум;

Q – түләнә торган айлар саны.

10. Министрлык башка бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларының шәхси счетларына күчерә.

11. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

стипендия билгеләнгән студентлар санына карата академик бурычлары булмаган, стипендия билгеләнгән студентлар саны мөнәсәбәте 100 процентка тигез;

гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының гомуми санында яшь укытучылар саны чагыштырма авырлыгы 25,5 процентка тигез.

12. Башкарма комитет Министрлыкка килешүдә каралган форма буенча һәм тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшырырга тиеш.

13. Башкарма комитет һәм вазыйфаи затлар тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатка ярашсыз файдалану өчен законнар нигезендә җавап тота.

14. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны законнар нигезендә Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы гамәлгә ашыра.

15. Башка бюджетара трансфертлардан максатка ярашсыз файдалану Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән акча суммасын законнарда билгеләнгән тәртиптә бәхәссез кайтаруга китерә.

16. Агымдагы финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар чираттагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Министрлыкның агымдагы финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, әлеге башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артык булмаган күләмдәге акча, муниципаль район бюджетының бу башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килгән чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен, ул элек бирелгән муниципаль район бюджеты кеременә чиратагы финанс елында кайтарыла ала.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәсә, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне саклап, Министрлык билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.